**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Ел җитәкчесе» республика җәмәгать конкурсы комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Ел җитәкчесе» республика җәмәгать конкурсы турында» 2002 елның 26 февралендәге ПУ-121 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2003 елның 12 мартындагы ПУ-201 номерлы, 2004 елның 25 мартындагы ПУ-223 номерлы, 2005 елның 21 февралендәге ПУ-57 номерлы, 2005 елның 30 июнендәге ПУ-274 номерлы, 2006 елның 19 гыйнварындагы ПУ-12 номерлы, 2006 елның 17 мартындагы ПУ-111 номерлы, 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-537 номерлы, 2008 елның 26 ноябрендәге ПУ-602 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-202 номерлы, 2010 елның 7 октябрендәге ПУ-665 номерлы, 2010 елның 9 декабрендәге ПУ-800 номерлы, 2011 елның 15 сентябрендәге ПУ-564 номерлы, 2012 елның 14 августындагы ПУ-652 номерлы, 2012 елның 28 ноябрендәге ПУ-1001 номерлы, 2013 елның 12 ноябрендәге ПУ-1109 номерлы, 2014 елның 20 декабрендәге ПУ-1160 номерлы, 2015 елның 28 маендагы ПУ-497 номерлы, 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы һәм 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Ел җитәкчесе» республика җәмәгать конкурсы комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан М.Г. Әхмәтовны, Т.П. Водопьянованы, А.Р. Зариповны, Р.А. Шәйхетдиновны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Җәббаров Марат Азат улын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрын;

Кузьмичева Елена Ивановнаны – Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе рәисен (килешү буенча);

Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын;

в) Комиссия әгъзасы Ш.Р. Агиевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе (килешү буенча)»;

г) Комиссия әгъзасы Ф.С. Габделганиевны Комиссия рәисе урынбасары итеп расларга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 14 декабрь
№ ПУ-748